АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
13.12.2023

**КАРАР**
223

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 13.10.2023 ел, № 205 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, 2023 елның 07 декабрендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм 2023 елның 07 декабрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 13.10.2023 ел, № 205 карарына үзгәрешләр кертергә (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә (http://fgistp.economy.gov.ru/).

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) хокукый акт текстны урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Козин Н.М.).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**